**Слайд 1 Балалар бакчасы-милли тәрбия бирүдә төп баскыч**

Республикабызда хәзер татар теле һәм рус телләре тигез хокуклы дәүләт телләре булып санала. Равил Фәйзуллинның күп еллар элек язылган бу шигыре бүген дә актуаль яңгырый:

**Слайд 2** Киләчәкнең башы-бүгенгедә
Нинди шатлык картлык көнендә
Оныкларың сиңа рәхмәт әйтсә
Матур итеп туган телендә
(Рәвил Фәйзуллин)

Без яшәгән заман- тирән үзгәрешләр һәм үзгәртеп корулар чорына туры килә. Заманнан артка калмас өчен мәктәпләрдә һәм балалар бакчасында белем һәм тәрбия бирү эшен федераль дәүләт таләпләренә туры килерлек итеп, балаларны белемле, акыллы, сәләтле итеп тәрбияләүгә зур игътибар сорала.
Милли тәрбия бирү, халык тарихын өйрәнү, аның мәдәни байлыгы турында күзаллау булдыру, туган теленә, халкына карата соклану, горурлану хисе тәрбияләү, балаларда ул яшәгән республика,авыл, шәһәр тарихы турында мәгълүмат бирүдән башлана. Һәр яктан үсеш алган киләчәк буын кешесе үссен дисәк, барлык тәрбия өлкәләрен дә кулланып, тәрбиягә нигез балалар бакчасындагы нәниләргә юнәлдерелгән.

Сл.3-6 2013нче елның сентябрь аеннан районыбызның һәр балалар бакчасында рус телле балаларны татар теленә һәм татар балаларын туган телгә өйрәтүдә Туган телдә сөйләшәбез (Ф.Хазратова) һәм “Татарча сөйләшәбез”укыту методик комплектлары кулланыла башлады .Бу УМК үз эченә күргәзмә һәм таратма рәсемнәр,битлекләр,аудио һәм видео язмалар,бармак театры, ,рус теленнән татар теленә тәржемә ителгән мультфильмнарны һәм эш дәфтәрләрен үз эченә ала.

**Слайд-7-9**

Эш дәфтәрләре балаларга татар сүзләрен истә калдырырга, аларны сүзтезмәләрдә һәм җөмләләрдә дөрес кулланырга бик нык ярдәм итә. Шулай ук тәрбиячегә дә материалны ныгытырга, эшчәнлеккә кызыксыну уяту, вакытында баланың хаталарын төзәтергә мөмкинлек бирә.Күп кенә ата-аналар дәфтәр белән эшне өйдә дә оештыралар.Бу баланың гына түгел, ә ата-аналарның да, балаларны өйрәтү сәләтләрен үстерү процессында

активлыгын арттыра башлады. Балалар бакчасы ата –аналар белән тыгыз элемтәдә эшли.

Мин,татар теле тәрбиячесе буларак, Казан шәһәрендә тьюторлар курсында укып кайттым. “АБВГДЕЙКа” балалар бакчасы УМК тормышка ашыру юнәлешендә эксперименталь мәйданчык буларак эш алып бара.

СЛ10 Безнең “АБВГДЕЙКа”балалар бакчасында туган телгә өйрәтү беренче кече яшьтән башлана. Ә татар теленә өйрәтү-уртанчылар төркемендә өйрәтелә башлый. Бакчабызда ике татар төркеме эшләп килә. Монда әлегә шөгыльләр рус телендә алып барыла,ә тәрбия өлеше татар телендә. Шулай ук бакчабызда озак еллардан бирле атнаның һәр чәршәмбесендә”Мин татарча сөйләшәм! дип аталган көн традициягә керде.Ул көнне һәр бакчадагы һәр хезмәткәр тулаем татарча сөйләшә.

Сл11Безнең «АБВГДЕЙКа» балалар бакчасында милли хис тәрбияләү түбәндәге юнәлешләрдән чыгып оештырыла:
-балаларга республика, туган як турында мәгълүмат бирү;
-халкыбызның гореф-гадәтләре белән тирәнтен таныштыру;
-әдәби һәм мәдәни байлыгыбыз турында кузаллау булдыру;
-туган телдә сөйләшергә теләк уяту, аны хөрмәт итү;
-төбәктә яшәүче язучылар, сәнгать кешеләре белән танышу;
-милли бәйрәмнәрнең тарихы белән таныштыру, аларда катнашу;
-халыклар, милләтләр арасындагы дуслык төшенчәсе барлыгын җиткерү.

**СЛ12** Балаларны татар теленә өйрәтү сыйфатлы, уңышлы булсын өчен, төркем тәрбиячеләре һәр эшчәнлектә катнашалар,материалны башка белем бирү өлкәләрендә дә кулланалар. Безнең “АБВГДЕЙКа” балалар бакчасы мисалында татар телле баларның белем сыйфаты 81 %, ә рус телле баларның – 78% тәшкил итә.

**Сл 13** Рус телле уртанчы төркемдәге балалар уку елы ахырында 62, зурлар төркемендә-45,мәктәпкә әзерлек төркемендә- 60 сүз үзләштерергә тиеш. Ә беренче сыйныфны тәмамлаган баланың лексик-минимум-225 сүз .Балаларның белем сыйфаты тәрбияченең белеменә,сәләтенә,аның педагогик осталыгына турыдан-туры бәйле.

Татар телендә дөрес сөйләшергә өйрәтү өчен, балаларны кызыксындыра алырлык аралашу даирәсе булдыру, сюжетлы уеннар оештыру, гомүмән, баланың актив сөйләмен үстерү зарур. Сөйләшергә өйрәтү өчен баланы мөмкин кадәр күбрәк аралашуга җәлеп итәргә тырышабыз.

Сл14-15 Иң беренче булып бакчабызда һәр төркемдә милли почмак булдырдык. Бу почмак Туган ягым-Татарстан дип атала. Анда балаларга

Татарстан, анда яшәүче күпмилләтле халык турында мәгълүмат бирү өчен төрле тематик һәм информацион материаллар тупладык: Татарстан символикасы, ил башлыкларының фотографияләре, Татарстан Республикасының башкаласы Казан шәһәре турында күргәзмә материал, язучылары, композиторлары турында мәгълүмат, Идел буе халыклары – татар, рус, чуваш милли киемнәр белән киенгән курчаклар, татар халык милли бизәкләре , дидактик уеннар, Идел буе халыкларының тарихы, мәдәнияте, көнкүрешен, милли киемнәрен чагылдырган папкалар булдырылды.

Ел әйләнәсе шөгыльләрдә һәм шөгыльдән тыш вакытларда балалар белән эшчәнлек татар халык уеннары, табышмаклар, бишек җырлары, җырлы - биюләр белән үрелеп бара. . Балалар белән ял вакытларында кече яшьтән үк бишек җырлары тыңлыйбыз, көйләп курчаклар йоклатабыз, төрле чәбәкәй уеннары уйныйбыз, санамышлар, тизәйткечләр, бармак уеннары өйрәнәбез. Рәсем ясау, әвәләү эшчәнлекләрендә милли җырлар тыңлап, алган хисләребезне рәсемдә чагылдырабыз, милли бизәкләрне кулланып төрле композицияләрне кисеп ябыштырып эшлибез, түбәтәй, калфак , алъяпкыч, читекләр бизибез. Бу эшләрне балалар аеруча яратып башкаралар. Без балаларны тәрбияләүдә режим вакытында бик еш әкият, сынамыш, санамыш, җырлы-биюле, хәрәкәтле уеннарны да киң кулланабыз

Сл16 Шуныы да әйтеп китү урынлы булырдип уйлыйм:әти-әниләр балаларына даими рәвештә “Салават күпере”журналын яздыралар. Бу журнал бай эчтәлекле һәм сыйфатлы.

**Слайд №17.** Бакчабызда кече музей эшләп килә,монда балалар халкыбызның үткәне, гореф-гадәтләре,йолалары белән таныша. Музей - балаларның яратып йөри торган урыны.

Сл18-19 Милли –мәдәни тәрбия бирүдә “Энҗе бөртекләре” түгәрәк эшчәнлегенең роле дә зур. Халкыбыз тарафыннан иҗат ителгән серле һәм мавыктыргыч әкиятләрне сәхнәләштереп уйнап, балалар уңай һәм тискәре сыйфатларны аерырга, әкият геройларының уй-хисләренә, эш- гамәлләренә дөрес бәя бирә белергә, мәрхәмәтле, рәхимле- шәфкатьле, ярдәмчел булырга өйрәнәләр. Әкият геройлары белән танышу аша аларның борчу-шатлыкларын, рухи халәтләрен аңларга өйрәнәләр, әдәп-әхлак кагыйдәләрен, тормыш тәҗрибәсен үзләштерәләр.

Сл20Милли хисләр тәрбияләүдә музыка шөгыленең дә әһәмияте зур. Балалар анда халык көйләрен тыңлап, үзләре дә матур җырлар өйрәнәр, милли биюләр бииләр.

Сл21 Төрле халыкларның милли бәйрәмнәре, гореф гадәтләре турында балалар белән әңгәмәләр үткәрәбез. Милли бәйрәмнәребез белән танышу ,гореф-гадәтләребезне барлау аша балаларбызда милли үзаң, милли традицияләргә мәхәббәт тәрбиялибез. Бу бәйрәмнәрдә халкыбызның гомер-гомергә эшчән, әдәпле, кунакчыл, ачык йөзле, михырбанлы булуын

күрсәтәбез. Аларның мәгънәле тормышын күрсәткән шөгыльләрен, һөнәрләрен, гореф-гадәтләрен балаларның күңелләренә салып калдырырга кирәк.

Сл22Мин район татар теле тәрбиячеләренең методик берләшмә җитәкчесе дә әле.Без район тәрбиячеләрнең белемен күтәрүне оештыру юнәлешендә максатчан эш алып барабыз , төрле темаларга семинарлар, үткәрәбез. Монда УМК авторлары белән очрашулар,масстер –класслар,түгәрәк өстәл артында сөйләшүләр,консультацияләр алып барыла

Сл 23-25 Бакчабызның рус телле тәрбиячеләре район күләм "Мин татарча сөйләшәм" конкурсында призлы урыннарга лаек булып,район данын яклыйлар.Шулай ук рус телле тәрбиячеләр,барысы да татар теле курсларында укып сертиффикат алдылар.
Шулай ук бакчабыз тәрбиячеләре Бөтенроссия,зона,республика конкурс-ярышларында катнашып күп кенә казанышлар яулый. Әле күптән түгел генә "Минем Татарстаным" конкурсына балалар бакчасыннан 7 эш тәкъдим иттек. Кино төшерү проектын тормышка ашыру өстендә эшлибез. Монда без рус мультфильмнарын татарчага тәрҗемә итеп, шөгыльләрдә кулланырлык кино ясау теләге көчле.
Бакчабыызныың һәр тәрбиячесе "Мәгариф","Гаилә һәм мәктәп"журналларыын өйгә алдыралар. Бу журналларда безнең тәрбиячеләрнең мәкаләләре бастырыылу нур өстенә нур өсти.
2015нче елда безнең балалар бакчасы Республика күләм "Билингваль балалар бакчасы" конкурсында җиңү яулап, 500 000 лек сертификатка лаек булды.
Ләкин бу уңышыбыз сабыйларны ике телдә камил сөйләшергә өйрәтү эшен туктатабыз дигән сүз түгел. Балалар дәүләт телләрендә камил сөйләшеп, кызыксынулары арта гына барсын, эшебезнең нәтиҗәсе булсын өчен яңа кызыклы ысуллар эзләячәкбез.

**Слайд №26-27** Бакчабызның тәрбиячеләре һәрчак эзләнүдә,җәмгыять белән бер аяктан атлыйлар.Бөтенроссия ,Татарстан,зона,район конкурсларында тәрбиячеләр әзерләгән балалар актив катнашып күп кенә мактау кәгазләренә ия булдылар. Быелгы уку елында гына да без "Татар малае" район конкурсында "Милли рухта тәрбияләнүче татар малае"номинацияясенә, Миллимультfest Республика балалар кинофестиваленең муниципаль этабында I дәрәҗә дипломга лаек булдык.Республика күләм "Сәяр" конкурсына Г.Камалның "Беренче театр" әсәрен сәхнәләштердек

Балалар бакчасында татар төркемнәре булуга карамастан, рус мохите хөкем сөрә. Тәрбиячеләр татар булса да, бөтен бала аңласын өчен русча сөйләшергә мәҗбүр. Балалар да үзара рус телендә аралаша. Чөнки күпчелек әти-әни гаиләдә туган телдә сөйләшми, шуңа да бакчага рус телле балалар килә. Минемчә, өйдә татарча аралашкан бала ана телен онытмый. Шулай ук ата-ананың телгә мөнәсәбәте нинди, баланыкы да шундый. Балам үз ана телен белергә тиеш дигән фикердәге ата-аналар, кызганыч ки, еш очрамый. Тәрбияченең үзенә генә баланы татарча яхшы итеп сөйләшү дәрәҗәсенә җиткерү мөмкин түгел, моңа гаиләнең дә ярдәме кирәк. Алар безгә йөз белән борылсыннар, туган телне бөтенебез дә бер дәрәҗәдә яратсак иде .

Туган телдә сөйләшергә өйрәтү гаиләдә башлана һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә дәвам итә. Ул балаларга ана телендә тәрбия һәм белем бирү өчен мөмкинлекләр тудыру, халкыбызның рухи байлыгына, мәдәниятенә якынайту шартларында алып барыла. Мәктәпкәчә учреждениеләр, мәгариф системасының беренче баскычы буларак, нәниләрне туган телгә өйрәтүдә башлангыч роль уйный.

Сл28-29

Яңа 2020-2021 нче ел Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителде.Бүгенге көндә икетеллелек өчен уңай шартлар тудыру дәвамлы булырга тиешлегенә һичкенә дә шигем юк.

**Татар кызы,татар уллары без,**
**Саклыйк,яклыйк туган илебезне.**
**Без көч биреп яшәтергә тиеш**
**Җандай якын туган телебезне!**

Без яшәгән заман- тирән үзгәрешләр һәм үзгәртеп корулар чорына туры килә. Заманнан артка калмас өчен мәктәпләрдә һәм балалар бакчасында белем һәм тәрбия бирү эшен федераль дәүләт таләпләренә туры килерлек итеп, балаларны белемле, акыллы, сәләтле итеп тәрбияләүгә зур игътибар сорала.

Милли тәрбия бирү, халык тарихын өйрәнү, аның мәдәни байлыгы турында күзаллау булдыру, туган теленә, халкына карата соклану, горурлану хисе тәрбияләү, балаларда ул яшәгән республика,авыл, шәһәр тарихы турында мәгълүмат бирүдән башлана.   Һәр яктан үсеш алган киләчәк буын кешесе үссен дисәк, барлык тәрбия өлкәләрен дә кулланып, тәрбиягә нигез балалар бакчасындагы нәниләргә юнәлдерелгән. Безнең «Акчэчэк» балалар бакчасында милли хис тәрбияләү түбәндәге юнәлешләрдән чыгып оештырыла:

-балаларга республика, туган як турында мәгълүмат бирү;
-халкыбызның гореф-гадәтләре белән тирәнтен таныштыру;
-әдәби һәм мәдәни байлыгыбыз турында кузаллау булдыру;
-туган телдә сөйләшергә теләк уяту, аны хөрмәт итү;
-төбәктә яшәүче язучылар, сәнгать кешеләре белән танышу;
-милли бәйрәмнәрнең тарихы белән таныштыру, аларда катнашу;
-халыклар, милләтләр арасындагы дуслык төшенчәсе барлыгын җиткерү.

Безнең балалар бакчасында балаларны милли региональ компонентлар белән таныштыру өчен уңай шартлар тудырылган. Төркемнәрдә милли почмакларыбыз бар: анда балалар туган төбәгебезне тулырак күзалласыннар өчен төрле папкалар, күрсәтмә әсбаплар әзерләдек. Мәсәлән, Татарстан һәм Россия дәүләт символлары, туган авылыбыз, башкаладагы истәлекле урыннарның фотографияләре.  Шулай ук Идел буе халыклары: мари, чуаш, удмурт, татар, рус, мордва, башкорт  киемле курчаклар, декоратив-гамәли сәнгать үрнәкләре сурәтләнгән альбомнар,  татар халык әкиятләре, уеннары, балалар матур әдәбияте, аудио һәм видеоязмалар, татарча мультфильмнар бар.

Ел әйләнәсе шөгыльләрдә һәм шөгыльдән тыш вакытларда балалар белән эшчәнлек татар халык уеннары, табышмаклар, бишек җырлары, җырлы - биюләр белән үрелеп бара. . Балалар белән ял вакытларында кече яшьтән үк бишек җырлары тыңлыйбыз, көйләп курчаклар йоклатабыз, төрле чәбәкәй уеннары уйныйбыз, санамышлар, тизәйткечләр, бармак уеннары өйрәнәбез. Рәсем ясау, әвәләү эшчәнлекләрендә милли җырлар тыңлап, алган хисләребезне рәсемдә чагылдырабыз, милли бизәкләрне кулланып төрле композицияләрне кисеп ябыштырып эшлибез, түбәтәй, калфак , алъяпкыч, читекләр бизибез. Бу эшләрне балалар аеруча яратып башкаралар.

Без балаларны тәрбияләүдә режим вакытында бик еш әкият, сынамыш, санамыш, җырлы-биюле, хәрәкәтле уеннарны да киң кулланабыз(мэсэлэн: “Чума Урдэкчума каз; Габдулла; Кэрия-зэкэрия:Тубэтэй;, татар халкының милли йолалары, гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре, бәйрәмнәрнең тарихы белән таныштырабыз. Көз көне балалар белән татар халкының яраткан бәйрәме –

“Сөмбелә” бәйрәмен, ә яз көне бакчадагы барлык балалар белән бергәләп “Нәүрүз” бәйрәмен уздырдык. Балалар бу бәйрәмдә татар милли киемнәрен киеп төрле уеннар уйнадылар. Мәсәлән, “Капкалы”,  “Күрсәт әле, үскәнем.”, “Кәрия-Зәкәрия”. Төрле бәйрәмнәр уздырганда балалар белән татарча җырлар, шигырьләр өйрәнәбез, әти-әниләр алдында матур итеп чыгыш ясарга тырышабыз. Шулай ук татар халкының борынгы йолаларыннан “Аулак өй”, “Сөмбелә”, “Каз өмәсе”, “Карга боткасы”, “Нәүрүз”, “Сабантуй” кебек күңел ачу кичәләрен балалар белән бергәләп үткәрдек. Бу кичәләргә кунак итеп әби-бабаларыбызны чакырабыз, алар белән татар халык уеннарын уйнадык: ”Йөзек салыш”, , “Чүлмәк сатыш”, “Ачык авыз” һ.б. Бу бәйрәмнәрне үткәргәндә балалар бик күп шигырьләр, җырлар, мәкаль-әйтемнәр, такмаклар өйрәнәләр.

Мәсәлән, Татарстан һәм Россия дәүләт с

Тарихны белү – ул үткән тормыш кына түгел, ә бүгенгесе дә. Үз милләтебезне генә түгел, ә милләтләр, халыклар арасындагы дуслык, тигезлек принцыбын үзләштергәндә генә, бары тик милли хисләр хөрмәт ителгән җирдә генә без яңа буында гуманлы, культуралы, чын мәгънәсендә әхлаклы, милләтенә, халкына хөрмәт белән карый торган кешеләр үсүен күрербез.